РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
АЛЬШЕЕВСКОАГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘЛШИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

18 март 2026 ел №2-12

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елгы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип таныйрга:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирелгән белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 09 сентябрендәге 34-1 номерлы карары.

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары

тарафыннан бастырып чыгару өчен  Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирелгән белешмәләр бирү тәртибенә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге Советының 2017 елның 09 сентябрендәге 34-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 22 июнендәге 23-2 номерлы карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Әлши авыл җирлеге башлыгы
В.Г.Михайлов